РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МОРДОВСКО-АФОНЬКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru:

**24 ноябрь 2022 ел** **№ 16**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

## «Биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында»

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указының 4 пункты, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 декабрендәге 89 номерлы «Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» карары нигезендә (һәм Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2022 елның 19 маендагы 63 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), **КАРАР БИРӘМ:**

1. Биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.И.Митяев

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 24 ноябрендәге
16 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
   - Башкарма комитет җитәкчесе;
   - Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;